

Шәһәр жиреннән аермалы буларак, авылда фельдшер булып эшләv икеләтә зур жаваплылык сорый торган һонәрләрнен берсе. Чонки, сер тvгел, бер vк вакытта аларга педиатр да, кvз врачы да, хирург та булырга туры килә. Тик, авылдашлар арасында абруй казаныр очен, белемле булу остенә ачык йозле, тәмле телле булу да бик моһим. Шокер, авылларыбызда әнә шундый гvзәл затлар эшли дә инде.
Кадошкино районы Большие Поляны халкы да фельдшердан бик унган. Фельдшер-акушерлык пункты фельд-шеры Светлана Петровна Тумпарова ин яхшы бәяләмәләргә лаек кеше. Зур Аланда һәм Насакан Потьмада яшәvчеләр һәрвакыт шундый сизгер медицина хезмәткәре булуына шат. 30 ел хезмәт эшчәнлеге дәверендә Светлана Петровна бик кvп кешеләргә тиешле һәм кирәкле медицина ярдәме кvрсәтте. Авыл халкы ана игелекле сvзе, кинәшләре очен дә, дәвасы очен дә рәхмәтле. Ул беркайчан да vз вакыты белән санашмый ярдәмгә ашыга. Әйе, авыл фельдшерында буш минутлары була да алмый. Әгәр кешегә начар икән, Светлана табиб тәvлекнен теләсә кайсы вакытында авыруга ярдәмгә ашыга; ял коне яки бәйрәм икәнлеген уйламыйча дәвалый, анын очен ин моһиме – авыруга ашыгыч ярдәм кvрсәтv.
Авыл жирлегендә ФАП - vзенчәлекле мини-поликлиника. Эш авыл жирле-гендә баштан ашкан, хоть отбавляй. Моннан тыш, ул берничә медицина белгечлеген бергә алып барырга тиеш: кан басымын да киметергә, ютәлне дә дәваларга тиеш. Үзе очен бу ялсыз һонәрне сайлаган кеше ин яхшысы дип саный һәм аннан башка яши дә алмый башлый. Светлана Петровна белән дә шулай була. Саранск медицина училищесын тәмамлаганнан сон, ул vзенен хезмәт биографиясен Кадошкино Үзәк дәваханәсендә хирургия, процедура һәм пост шәфкать туташы булып башлый. Бу эшләр ана ошый да һәм аларны булдыра да. Кыскасы, хезмәттәшләренен, авыруларнын хормәтен яулый.
Бvген Большие Поляны ФАПында Светлана Петровна бервзе эшли. Ана торле яшьтәге авыл кешеләре морәжәгать итә, әмма ин еш килvчеләр - хроник авырулары булган олкән кешеләр, барыннан да бигрәк йорәк-кан тамырлары авыруларыннан интеккәннәре, кечкенә балалары булган әниләр. Авыл медигына ике торак пунктта яшәvче 500дән артык кешегә хезмәт кvрсәтергә туры килә, шуларнын 178-се пенсионер. Уртача алганда, коненә ун кеше морәжәгать итә. Әмма ОРВИ белән авыручылар булганда,

авыл медигына егерме пациент кабул итәргә туры килә. Мәсәлән, авыл ФАПында кабул итvнен бер конен алыйк... Менә беренче пациентка: Роза Идрисовна Тугушева процедурага килгән. Башта фельдшер авырунын хәлен һәм даруларга реакция турында жентекләп сораша. Роза ханым кичерешләре турында Светлана Петровна белән уртаклаша, ә доктор, vз чиратында, аны игътибар белән тынлый һәм кирәкле кинәшләр бирә. ФАПтагы процедуралардан сон, фельдшер сабыйлар патронажына киттә. Бер яшькә кадәр оч бала анын карамагында. Нигездә, Светлана Петровна олкән яшьтәге кешеләргә, балаларга йори, әмма яшь авыл кешеләре дә нинди дә булса хәлсезлекләре белән еш морәжәгать итә. Аларга да «авыл табибы» ярдәмгә ашыга.

- Безнен фельдшерыбыз – белемле белгеч; сизгер, игътибары, кешелекле Кеше, - ди киләсе рәхмәтле пациенты Сара Ибраһим кызы Долотказина.

Светлана Петровнаны барысы да мактыйлар: игелекле, ачык йозле, ихтирамлы, яхшы белгеч, диләр. Теләсә кайсы вакытта ана шалтыратырга була, дип сойлиләр; ул беркемгә дә ярдәменнән баш тартмый. Пациентларны кабул итv арасындагы тәнәфесләрдә медицина хезмәткәре Светлана Тумпарова vз эше турында, авылда vз сәламәтлегенне даими рәвештә кайгыртырга кирәклеге, диспансеризацияне вакытында vтәргә тиешлеге турында сойли, әнгәмәләр vткәрә, диспансеризациягә юнәлтә. Еш кына авыруны vзе Кадошкино поликлиникасына озата бара. Менә шулай авыл медигы эш кононен берничә сәгате уза. Халык белән эшләv кыенлыгын барыбыз да белә, әмма С.П.Тумпарова vз юлын тапкан, хормәт яулаган һәм шунын очен авылдашлары аны кадерли. Тагы Светлана Петровна оч матур кызнын искиткеч әнисе, кайгыртучан хатыны, унган хужабикә, дип әйтмәсәк, бу искиткеч игелекле, жаваплы һәм бик тыйнак хатын-кыз турында язмабыз тулы булмас иде. Эш урынында да, vз хужалыгында да тулы тәртип.

Июнь аенда Светлана Петровна vзенен Алтын Юбилеен билгеләп vтәчәк. Сина озын гомер, бәхет-шатлыклар, жан тынычлыгы, тән сихәте, саулык-сәламәтлек телибез. Һаман шулай кочле рухлы һәм ярдәмчел, изге кvнелле, балаларыннын һәм оныкларыннын игелеген кvреп озак яшәргә насыйп булсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә торенеп яшә. Һәм бу конне ана тагы бик кvп жылы теләкләр юлланыр дип ышанам. Әлбәттә, һәркем рәхмәтләрен әйтер. Ана мондый алыштыргысыз, кирәкле кеше булганы очен рәхмәт. Чонки авылда фельдшер - һонәр генә тvгел, ул каты ритмга һәм авыл халкынын сәламәтлегенә буйсына торган тормыш рәвеше дә.

Наилә Насырова